ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУЛЬМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Мульма, ул. Центральная, 46а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МҮЛМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк ур., 46а

тел./факс 8(84365) 70-2-03, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**5 апрель, 2023 ел** **№ 5**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитетының «Бердәм тариф челтәре кагылмый торган баш бухгалтерлар һәм бухгалтерлар, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең, Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитетының хәрби-исәп хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2019 елның 11 ноябрендәге 24 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәткә түләүне тәртипкә салу максатларында, хәрби-исәп хезмәткәрләренә түләүне оештыру һәм шартлары Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 2014 елның 23 апрелендәге 255 номерлы боерыгы нигезендә билгеләнүен исәпкә алып, Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитетының «Бердәм тариф челтәре кагылмый торган баш бухгалтерлар һәм бухгалтерлар, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең, Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитетының хәрби-исәп хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2019 елның 11 ноябрендәге 24 нче номерлы карарына (26.12.2019 № 27, 30.09.2020 № 26, 29.10.2020 № 27 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Карар исемендә: «хәрби-исәп хезмәткәрләренең» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) «Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлегенең хәрби-исәп хезмәткәрләренең (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләү турында нигезләмә» дип аталган 2 нче кушымтаны гамәлдән чыгарырга;

3) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитетының «Бердәм тариф челтәре кагылмый торган баш бухгалтерлар һәм бухгалтерлар, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең, Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитетының хәрби-исәп хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2019 елның 11 ноябрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр

кертү хакында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 30 ноябрендәге 8 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

4) Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Мүлмә авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р. Зиннәтуллин